

Момкинлекләре чикле кешеләргә яр-дәм итv - Мордовиядә 3 декабрьдән 12 декабрьгә кадәр уза торган Инвалидлар декадасынын топ максаты. Унконлек кысаларында инвалидлар очен торле чаралар, хәйрия кичәләре һәм концертлар vткәрелә. «Момкинлекләре чикләнгән кешеләр тулы канлы тормыш белән яшәргә, спорт белән шогыльләнергә, ижади конкурсларда катнашырга тели», - ди Анна Базаева. Мәгариф отличнигы, ул гомеренен 14 елын Темниково балалар интернат-йорты балаларына багышлаган.
Педагог «Темниковские известия»гә биргән хатирәләрендә болай ди: «Язмыш мине балалар йорты белән бер генә тапкыр бәйләмәде. Сугыштан сонгы авыр вакытта әтием Темников балалар интернат-йортында эшләде, - дип сойли Анна Ильинична. - Безнен гаиләгә интернатнын мунча ишегалдында-предбанникта яшәргә рохсәт иттеләр. Хәтерлим әле, мунча коннәрендә балалар йортында эшләvче хатын-кызлар су ташыганда, бездә бик салкын иде, без юрган астына яшеренә идек».      Тормыш vз чираты белән барды. Без балалар йортыннан килгән балалар белән дус булдык: бергәләп уйнадык, кинога йордек. Биредә сугыш вакытында ятим калган балалар тәрбияләнә иде. Сонынннан безнен гаиләгә Сталин исемен йорткән балалар йортынын подвал бинасында фатир бирделәр. Берничә елдан әтине кыскарттылар, һәм безнен гаилә Старый Шукстелимгә китәргә мәжбvр була. Мин югары сыйныфларда укыдым, шуна кvрә Темникта калдым. Башта бер абый янында, аннары икенчесендә яшәдем. Кvп укыдым, яхшы укырга тырыштым, югары белем турында хыялландым. 1968 елда педагогия институтын тәмамладым. Монын очен бик кvп кыенлыкларны жинәргә туры килде, бигрәк тә матди яктан. Энем Иванны армиягә озат канда, китәр алдыннан ул мина унбер сум бирде. Мин бәхеттән «жиденче кvктә» булдым! Шунын беразына vземә кием сатып алдым. Мин бик тырышып, стипендиягә укыдым, шуна кvрә кечкенә генә очлек алырга да vземә рохсәт итә алмадым».
Педагогик институтны тәмамлаганнан сон, Анна Ильинична 13 ел Канаково укучыларын немец теленә ойрәтә, аннары 3 ел Темниково район мәгариф бvлегендә хезмәт укыту буенча инспектор, 8 ел - балачак хокуклары буенча инспектор булып эшли. Узган гасырнын 90 нчы елларында, лаеклы ялга чыкканчы, хезмәт куйган балалар йортына олкән тәрбияче булып кvчкән.
Темников балалар интернат-йорты узган гасырнын 30 нчы еллар уртасында ачылган иде. Анда физик яктан тайпылышлар аркасында әти-әниләре нарасыеннан баш тарткан балалар тәрбияләнгән. Башта алар, оч яшькә кадәр Бала йортында тәрбияләнгән, ә

аннан сон Темников балалар интернат - йортына эләгә.
«Мин балалар йортында эшләгән елларда 50шәр, 70әр бала булды. Аларга ата-аналарын тәрбиячеләр, медицина һәм хезмәт кvрсәтvче персонал алмаштырды: туган коннәрен билгеләп vттеләр, бәйрәмнәр, танып - белv викториналары һәм кvнел ачу концертлары оештырдылар, - дип искә ала балалар белән эшләv елларын А.И.Базаева. - Без Ф.Ф.Ушаков исемен йорткән туган якны ойрәнv музеена бара идек, мәдәният йортындагы концертларга. Саранскка, мәсәлән, Степан Эрьзя скульптуралары кvргәзмәсенә, Саровка - Изге Серафимга экскурсияләр белән йордек. Безнен спонсорлар - ВНИИЭФ хезмәткәрләре бик жылы каршы ала торган иде. Аларнын һәркайсынын vз тәрбияләнvчесе бар иде, аларга бvләкләр тапшырдылар. Шул вакыт балалар бик тә бәхетле булалар! Әмма балалар йортында аларны ничек кенә яхшы карамасалар да, ата-аналы булырга һәрвакыт теләделәр. Тәрбияләнvчеләр телевизордан «Кот ми-не» тапшыруын карарга яраттылар. Бигрәк тә Игорь Кваша алып барган вакытта аларга ошады. Балалар, әти-әниләрен тапкан бәхетле балаларны кадерләп карый торган иделәр».
Балалар йортында тәрбияләнvчеләр, бигрәк тә чыгарылыш сыйныф укучылары, әти-әниләрен табу очен, олкән тәрбиячегә морәжәгать итәләр. Анна Ильинична да аларны эзләп таба, хатлар яза, ботен Россия буенча запрослар жибәрә, жаваплар ала. Аннары аларнын йорәкләренә барып житәргә тырыша. Әти-әниләренен балаларына бик кирәк икәнен анлатасы килә. Шатлык очраклар да булды, кайчагында бу момкин тумый да иде.
Беренче бәхетле Андрей Кравцов булды. Анын әти-әнисе Амур олкәсендә яшәгән һәм улларынын исән булуын белмәгән. Алар очен бу шок булды. Мәктәпне тәмамлаганнан сон Андрейны Потьмага кадәр озаттылар, поездга утырттылар, ә шәһәрдә аны әти-әниләре каршы алды.
Тагы Женя А. vтенече буенча, әнисен эзләп таптык. Ул Саранскида яши һәм хәзер алар аралаша. Шулай Аня Хайко Тvбән Новгородта яшәгән абыйсын эзләп таба. Юлия Савостикова Красноярск краенда яшәvче сенелләрен тапты. Ел саен Юля алар янында була. Татарлар очен хас булмаган очрак турында да хәбәр: Эльвира Знын әнисе Казанда яши һәм кызы эзләве турындагы хатка болай дип жавап биргән: нигә аны борчыйлар, ул бит баласыннан баш тарткан кәгазь язган булган... Аннан аралашу барыбер булган, әмма теләгәнчә жылы булмаган. Володя И. очен дә туганнары табылган. Беренче кичтә алар кем икәнлекләрен ача алмый. Ә иртән Володя аларнын оныклары булу турында сойләргәннәр. Әби-бабай оныкларынын әнисе исән, әмма аны борчырга кирәкми, дигәннәр - анын яна гаиләсе һәм уллары бар. Мәктәпне тәмамлаганнан сон Володя инвалидлар очен интернатка китә, чонки аны берәv дә оенә алмый; ике тапкыр туганнары аннан баш тарта.
«Хочется пожелать всем детям в семьях и детских домах отзывчивых взрослых, - говорит напоследок А. И. Базаева. - Чтобы и родители, и воспитатели любили их, дарили им только радость и добрые слова».
Без, ярдәмгә мохтажларга, билгеле коннәрдә генә тvгел, ә һәрвакыт ярдәм итv турында онытмаса идек.

**Н.ХӘЛИЛ** әзерләде